ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КАЛМАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

# КАРАР

“08” ноябрь 2024 ел Игенче авылы № 4

“Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмаш авыл җирлегенең Игенче авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында”

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы “Калмаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә

## КАРАР БИРӘМ:

1. Тукай муниципаль районы Калмаш авыл җирлегенең Игенче авылында 2024 елның 21 нояберендә 18.00 сәгатькә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләләрне расларга:

“Калмаш авыл җирлегенең Игенче авылы территориясендә 2025 елда балигъ булган, Калмаш авыл җирлегенең Игенче авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешегә 1000 ( мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, ялгыз карт гражданнарга һәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча түләүдән азат итәргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Игенче авылы юлларын ремонтлау (асфальт валчыклары сатып алу);
- урамнарны яктырту (электр материаллары сатып алу, Игенче авылында урамнарны яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыру);

“ӘЙЕ” “ЮК”.

3. Татарстан Республикасы, Тукай районы, Калмаш авылы, Центральная урамы, 32 йорты СДК “Яшлек” каршында гражданнар җыенын үткәрергә.
4. Тукай муниципаль районы Калмаш авыл җирлеге башкарма комитетын Гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.
5. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.
6. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында “авыл җирлекләре”(https://tukay.tatarstan.ru/) бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында(http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.
7. Әлеге карар халыкка җиткерелгән көннән үз көченә керә.

Калмаш авыл җирлеге Башлыгы Ф.В.Шәвәлиев